КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 апрель г.Казань № 383

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 316 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 316 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 26 гыйнвар, 20 нче; 2007 ел, 28 апрель, 149 нчы; 2008 ел, 28 гыйнвар, 38 нче; 2008 ел, 25 июль, 534 нче; 2009 ел, 5 март, 125 нче; 2009 ел, 8 май, 283 нче; 2010 ел, 10 декабрь 1033 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 533 нче; 2012 ел, 10 март, 205 нче; 2012 ел, 9 июнь, 503 нче; 2013 ел, 18 март, 175 нче; 2013 ел, 30 ноябрь, 946 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 254 нче; 2014 ел, 1 ноябрь, 842 нче; 2015 ел, 2 октябрь, 736 нчы; 2016 ел, 23 март, 157 нче; 2016 ел, 28 июль, 523 нче; 2016 ел, 17 август, 568 нче; 2016 ел, 7 декабрь, 904 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 971 нче; 2017 ел, 27 март, 188 нче; 2017 ел, 29 август, 611 нче; 2017 ел, 22 сентябрь, 711 нче; 2018 ел, 25 май, 398 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1215 нче; 2019 ел, 24 июнь, 509 нчы; 2019 ел, 25 июль, 619 нчы; 2019 ел, 13 ноябрь, 1038 нче; 2020 ел, 3 февраль, 68 нче; 2021 ел, 20 июль, 607 нче, 2021 ел, 17 ноябрь, 1095 нче, 2022 ел, 24 гыйнвар, 44 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аппарат буенча –вазыйфаи окладлар буенча 165 берәмлек күләмендә айлык хезмәт хакы фонды белән 3 675,5 мең сум күләмендә, шул исәптән хезмәт хакы буенча 32,2 мең сум күләмендә айлык хезмәт хакы фонды белән «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кооперациясен үстерү буенча компетенцияләр

үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Буа ипподром белән» дәүләт завод ат абзары» дәүләт учреждениесе, «Чистай ипподром белән» дәүләт бюджет учреждениесе һәм «Минзәлә ипподром белән» дәүләт завод ат абзары» дәүләт учреждениесе бухгалтерлык исәбен алып бару, бухгалтерлык хисабын формалаштыру һәм хезмәткәрләренә хезмәт хакын исәпләү максатларында 2 берәмлек күләмендә;»;

өченче абзацта «462», «6 845,747» саннарын тиешенчә «516», «8 425,1» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 3.4 пункт өстәргә:

«3.4. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кооперациясен үстерү буенча компетенцияләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Буа ипподром белән» дәүләт завод ат абзары» дәүләт учреждениесе, «Чистай ипподром белән» дәүләт завод ат абзары» дәүләт учреждениесе һәм «Минзәлә ипподром белән» дәүләт завод ат абзары» дәүләт бюджет учреждениесе бухгалтерлык исәбен алып баруны, бухгалтерлык хисабын формалаштыруны һәм хезмәткәрләренә хезмәт хакын исәпләүне гамәлгә ашыра.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы структурасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2005 ел, 6 июль, 316 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 21 апрель, 383 нче
карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы структурасы**

